БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» 11 2025ел № 307

«2026-2030 елларга Балтач муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе субъектларына торак һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итү» федераль проектын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» региональ проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «2026 - 2030 елларга Балтач муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка житкерергә (http://baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты житәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Житәкче А.Ф.Хәйретдинов